КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 14 декабрь г.Казань № 1133

Татарстан Республикасының Пространство белешмәләре фонды турында

«Геодезия, картография һәм пространство белешмәләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 30 декабрендәге 431-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коммерциячел булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Пространство белешмәләре фондын булдырырга.
2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасының Пространство белешмәләре фонды» дәүләт бюджет учреждениесен төзү турында тәкъдимен кабул итәргә (алга таба – Учреждение).
3. Учреждениене гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы гамәлгә ашыра дип билгеләргә.
4. Учреждение эшчәнлегенең төп максатын Татарстан Республикасының Пространство белешмәләре фондын, географик объектларының бердәм төбәк электрон картографик нигезен һәм атамалар каталогын алып бару дип билгеләргә.
5. Учреждение хезмәткәрләренең чик штат санын 24 берәмлек күләмендә билгеләргә.
6. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына:

компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы эшчәнлеген җайга сала торган норматив хокукый актларга тиешле үзгәрешләр кертергә;

10 көн эчендә Учреждение уставын расларга һәм аны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә;

Учреждение уставын дәүләт теркәвенә алган көннән алып җиде көн эчендә Учреждение эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Учреждениегә беркетергә, башка кирәкле оештыру чараларын үткәрергә;

ел саен Учреждение өчен аның уставында каралган төп эшчәнлек төре нигезендә дәүләт йөкләмәсен расларга.

7. Учреждение тарафыннан эшләр башкаруга дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 елның 31 декабрендәге 1044 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында Учреждениегә каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

8. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән берлектә Учреждение уставын дәүләт теркәвенә алган көннән алып 45 көн эчендә Учреждение тарафыннан дәүләт эшләрен (хезмәт күрсәтүләр) башкаруга (күрсәтүгә) норматив чыгымнар эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслау өчен тапшырырга.

9. Учреждениегә өч ай эчендә Учреждение вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек регламентын эшләргә.

10. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә пространство мәгълүматлары инфраструктурасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2012 ел, 26 март, 239 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында тиешле тәкъдимнәр кертергә.

11. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанслар һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин